һәм нәтиҗәле эшли торган юнәлешләрнең берсе [3: 28]. Тел берәмлекләренең территориаль таралышын өйрәнү аерым телләрдәге һәм тел берлекләрендәге билгеләрне синхрон һәм диахрон аспектта анализлау мөмкинлеген тудыра. Ареаль лингвистика фәненең метод һәм алымнары диалектларны тарихи сәбәпләргә бәйле катлаулы һәм каршылыклы система буларак өйрәнү юлларын ача [4: 2]. Ф.Йосыпов, беренчеләрдән булып, фигыльләрнең татар сөйләшләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен ареаль таралышка бәйләп анализлый. Телнең чагыштырмача тотрыклы ярусларыннан исәпләнгән авазлар системасын да ареаль аспектта өйрәнү тел һәм халык тарихына бәйле күп кенә сорауларга җавап табарга ярдәм итә. Рязань өлкәсеннән алып Көнбатыш Себергә кадәр таралган татар сөйләшләренең һәрберсенә хас тел күренешләренең үзенчәлекләренә аңлатма бирү өчен, тел системасын тәшкил итә торган һәрбер структур элементка анализ бирү сорала. Татар әдәби теленә һәм аның барлык сөйләшләренә хас сузык авазлар татар милли телен система буларак тасвирлауда файдаланыла торган элементларның берсе булып тора. Бербөтен татар милли телен тәшкил итә торган сөйләшләрне һәм әдәби телне сузык авазларга бәйле чагыштырып өйрәнү аларның охшаш яки аермалы билгеләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Татар теленең сузык авазлар системасында сөйләшләрне бер-берсеннән аера торган күренешләрнең берсе – [а] авазы кулланылышы. Әлеге аваз татар диалект теленең моделен төзи торган мөһим бер элемент – хосусый бер система.

Хәзерге төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең дә фонетик төзелеше күп гасырлар дәвамында формалашкан. Әлеге процесс төрки телләрдә төрле юнәлешләрдә бару сәбәпле, тартык һәм сузыкларга, шулай ук [а] авазына да бәйле үзенчәлекләр барлыкка килгән. Татар телендә закончалыклы күренешләрдән исәпләнгән [а] авазының берничә вариантта кулланылышы тел үсешенең тарихын, динамикасын билгеләргә булыша. Әдәби телне һәм күпсанлы сөйләшләрне [а] авазы вариантларына нигезләнеп тикшергәндә, һәр вариантның билгеле бер ареалда, бер яки бердән артык сөйләштә таралыш алганлыгы күзәтелә. Әлеге тел күренешен төрки телләр яссылыгында карау гомумтөрки системада татар теленең урынын ачыкларга ярдәм итә. Шул рәвешле, [а] авазының берничә варианты кулланылуы татар телен генә түгел, ә төрки телләрне характерлый торган төп билгеләрнең берсе булып тора. Ә төрки телләр өчен «мәҗбүри булмаган» вариантлар аерым сөйләшләрне башкаларыннан аера торган дифференциаль билге ролен башкара.

[а] авазының татарларның этник составына бәйле булган вариантлары таралган ареалларны картада тамгалап чыгу халыкның географик таралышын, башка милләт вәкилләре белән бәйләнешләрен, шул аралашуларның нәтиҗәләрен анализларга мөмкинлек бирә. Аерым очракларда теге яки бу вариант кулланылышы тарихи фактлар ярдәмендә генә аңлатыла ала.

Бу өлкәдә фәнни эзләнүләр чынбарлыктагы күренешләрне үсеш-үзгәрештә, үзара бәйләнештә тикшерә торган диалектик метод; тел берәмлекләрен өйрәнүнең ареаль, лингвогеографик, изоглоссалау, картографияләү, шәрехләү, чагыштырма-тарихи методлары ярдәмендә алып барыла. Шулай ук системалылык һәм тарихилык принципларына таяныла.

Татар теленең бер фонетик үзенчәлеге булган [а] авазының төрле вариантларда кулланылуын комплекслы рәвештә ареаль аспектта өйрәнү аларның барлыкка килү сәбәпләрен, үсеш-үзгәрешен ачыклауга нигезләнә. Зур күләмле фактик материалны анализлау нәтиҗәләре татар милли телен система буларак тасвирлауда, ареаль лингвистика фәнен үстерүдә, тел тарихын яктыртуда гамәли һәм теоретик яктан әһәмияткә ия, ягъни алар татар теленең фонетик үзенчәлекләрен, татар теле тарихын өйрәнүгә багышланган махсус курсларның гыйльми ягын тирәнәйтә.

Татар телендәге [а] авазының фонетик вариантлары тел галимнәренең игътибарын күптән җәлеп итеп килгән. [а] авазының иренләшү күренеше тел гыйлемендә җентекле тикшерелгән. Г.Алпаров, Л.Җәләй, Н.Борһанова, Җ.Киекбаев, Д.Рамазанова, Г.Сөнгатов, Ф.Йосыпов һ.б. тарафыннан татар сөйләшләрендә [а] авазының төрлечә әйтелешенә аңлатма бирелгән. Г.Алпаровның «Сайланма хезмәтләре»ндә [а] авазының иренләшүе схемада күрсәтелә. Җ.Киекбаев «Башкорт теле фонетикасы»нда, татар теленнән аермалы буларак, башкорт телендә [а] авазының иренләшү сәбәпләрен шул схемага нигезләнеп аңлата. Аның фикеренчә, башкорт сөйләшләренең көнбатыш өлешендә [а]

авазының иренләшүе күрше татар теле йогынтысында барлыкка килгән. Л.Җәләй [а] фонемасының иренләшүен а>о авазлар күчешендәге бер этап буларак карый [5]. В.Богородицкий тарафыннан бу күренеш татар теленең рус теленнән аермасы төсендә раслана. Ф.Исхаков та татар телендә [а] авазының иренләшүен искәртеп, аны татар, башкорт телләрендә тел арты [к], [г] авазлары белән бәйли [6: 66]. Б.Серебренников һәм Н.Гаджиева фикеренчә, татар һәм башкорт телләрендә [а°] авазы чуваш телендәге тарихи фонетик процесс – а>о>у авазлар күчеше – белән аңлатыла. Чуваш теленең югары диалектында «о» баскычында тукталып, түбән диалектта «у» га үзгәрүе 1236 елдагы яудан соң Идел-Чулман төбәгендә яшәгән болгар-чуваш халкының аерылу-бүленүе белән бәйләп карала. Ш.Мәрҗани, Н.Ашмариннан аермалы буларак, болгар һәм чуваш халкын тәңгәлләштерми. Аның фикеренчә, болгарлар һәм чувашларның телләрендә охшаш элементлар бу халыкларның телләре һәм яшәү ареаллары якынлык белән бәйле [7: 89].

Татар теле белемендә тупланган материаллар, экспедиция нәтиҗәләренә нигезләнеп, [а] авазының сөйләш һәм диалектларның уртак сыйфатын яки аермалыкларын билгели торган биш төрле вариантта кулланылышы ачыкланды. Иҗтимагый күренеш буларак, тел халыкның рухи һәм матди мәдәнияте, икътисади, сәяси шартлары, тарихы һәм таралыш географиясе белән бәйле.

*[о$^{a}$] – нык иренләшкән вариант.* Аның кулланыла торган территориясе чагыштырмача зур түгел: Шушма, Бура (Сәрдек) елгалары бассейны, Казан һәм Мишә елгаларының өске агымында урнашкан мамадыш сөйләшенең төньягы, балтач сөйләшләре.

Нык иренләшкән [о$^{а}$] авазы сүз башы һәм беренче иҗектә киң, иренләшкән [о] авазына бик якын әйтелә: *о$^{а}$й, мо$^{а}$л, бо$^{а}$л, то$^{а}$л, о$^{а}$йо$^{а}$з, то$^{а}$лло$^{а}$рга°* [8: 76]. [а] авазының казан арты сөйләшләренә хас [а°] варианты белән чагыштырганда нык иренләшкән варианты, Н.Борһанова фикеренчә, соңрак барлыкка килгән.

Удмурт теленнән кала, Идел-Чулман телләренең барысында да (татар, башкорт, мари, чуваш) сүзләрнең беренче иҗегендәге [а] авазы үзгәреш кичергән: татар телендә [а°], чуваш теленең югары диалектында [о], түбән диалектында [у], мари телендә [о] авазына күчкән [9]. Чуваш теленең мари теле белән янәшә таралган иң төньяк сөйләшләренә аеруча о-лаштыру хас. Изоглоссалардан күренгәнчә, татар халкының дә озак вакытлар мари халкы белән аралашып, янәшә яшәгән территорияләре нык о-лаштыру белән характерлана. Бу үзенчәлекне Л.П.Грузов чуваш халкының килеп чыгышына таянып аңлата: «Идел буе Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, халыкның бер өлеше суваз кабиләсе тирәсендә тупланып, җирле фин-угор кабиләләрен ассимиляцияләп, чуваш халкына нигез сала. Ә калган өлеше кыпчак кабиләләре белән катнашып, татар һәм башкорт халыкларының нигезен тәшкил итә» [10: 41].

Күренә ки, татар теленең казан арты сөйләшләре төркеменең төньягында һәм чуваш теленең югары диалектында [а] авазының нык иренләшкән варианты кулланылу – мари теле субстраты, ягъни, болгар кабиләләре тарафыннан ассимиляцияләнгән мари кавемнәре җирле халык теленә йогынты ясаган. Н. Борһанова, казан арты төбәгенең әлеге сөйләшләре таралган урыннарда яшәүчеләрнең озак вакытлар дәвамында мари һәм удмурт халыклары белән тыгыз элемтәдә булуын, шул территориядәге һәр авылда диярлек нәселләре мари яки удмуртларга барып тоташкан гаиләләр барлыгын искәртә [8: 79]. Бу хакта мәгълүматлар А.Халиков хезмәтләрендә дә күзәтелә [11: 38]. Казан артында Ашыт, Шушма, Казан елгалары буендагы күпсанлы топонимнар шуны раслый. И.Износков та Казан губернасының Мамадыш өязендәге халыкларның этнографик яктан «чуар» булуын ассызыклый. Кайбер авылларга удмурт яки марилар нигез салган булып, вакытлар узу белән, алар татарлар белән катнашып яши яки бөтенләй татарлашкан дигән карашта тора автор [12: 77].

Димәк, казан артының төньяк районнарында (балтач, мамадыш сөйләшләренең төньягы) нык о-лашкан [о$^{а}$] фонемасы мари теле субстраты йогынтысы белән аңлатыла. Мари теле, гомумән, о-лаштыручы тел буларак [13], уртача иренләшкән [а°] фонемасы характерлы булган болгар компонентлы татар теленә тәэсир итеп, беренче иҗектәге [а] авазының о-лашу процессы дәвам итүгә этәргеч булган.

Нык иренләшкән вариант тубыл-иртыш диалектының тубыл, тевриз сөйләшләрендә дә бар. Бу очракта сүз җирле халык сөйләменә бирегә күчеп утырган бохарлылар телендә

булган үзенчәлек кушылу нәтиҗәсе турында бара [14: 37].

*Уртача иренләшкән [a°].* Әлеге вариант акустик һәм артикуляцион сыйфаты ягыннан әдәби телдәге [a] авазына якын: арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшү төсмере белән әйтелә. Урта диалектның күпчелек сөйләшләренә хас булган бу фонетик үзенчәлекнең таралыш изоглоссалары шактый зур территорияне били: казан арты сөйләшләре төркеме, тау ягы сөйләшләре төркеме, минзәлә сөйләше. Ул, [a] авазының башка вариантлары белән беррәттән, Татарстаннан читтә оренбург сөйләшенең ык, каргалы, бузулук, бәшир урынчылыкларында һәм себер татарлары тубыл-иртыш диалектының кайбер урынчылыкларында очрый.

[a] авазының иренләшүе белән бәйле югарыда китерелгән аңлатмага нигезләнеп, уртача иренләшкән [a°] авазының билгеле бер татар сөйләшләрендә кулланылышын болгар теле субстраты йогынтысы һәм a>a°>o авазлар күчешенең кыпчак кабиләләре белән аралашу процессында тәмамланмый калу нәтиҗәсе дип карарга мөмкин. Уртача иренләшкән [a°] авазының күзәтелү үзәге булып элеккеге Идел буе Болгар дәүләте чикләре торса, оренбург, себер татарлары сөйләмендәге аның утрау-изоглоссалары 1552 елдан соң бу төбәккә казан татарларының берничә дулкын булып күчеп утырулары белән аңлатыла.

*[a] – ачык, мишәр диалекты вәкилләре сөйләшенә хас вариант.* Түбәндәге характеристикага ия: арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән. Төрле сөйләшләрдә өлешчә арткырак яки алгырак рәт әйтелешле варианты да очрый, мәсәлән, хвалын сөйләшендә гадәттәгедән арткырак рәт [a] авазы күзәтелә. Кайбер урынчылыкларда ул иренләшү төсмере белән әйтелә (хвалын, мордва-каратай сөйләшләре), ләкин әдәби телгә һәм урта диалектның күпчелек сөйләшләренә хас уртача иренләшкән [a°] авазыннан ерак тора [15: 32].

[a] авазының әлеге варианты, Мокша, Цна елгалары бассейннарында формалашкан мишәрләрнең төрле елларда билгеле бер сәбәпләр аркасында күпләп күчеп утыруы сәбәпле, зур территориядә таралыш алып, түбәндәге изоглоссаларны барлыкка китергән: темников, ләмбрә, кузнецк, хвалын, стәрлетамак, сергач, чүпрәле, мордва-каратай, чистай, мәләкәс, байкыбаш, шарлык сөйләшләре. Бу үзенчәлекнең киң таралышы төрле елларда билгеле сәбәпләр аркасында күчеп утырулар белән бәйле.

Л.Мәхмүтова карашынча, Мокша һәм Цна елгалары буйларына XI гасырга кадәр үк борынгы кыпчак кабиләләре килеп утырган. Аларга хәзерге караим, балкар, кумык һәм Codex Cumanicus, XVI-XVII гасырларда кыпчак телендә язылган истәлекләрне үз ядкяре итеп саный торган барлык халыкларны да кардәш дип санарга мөмкин [15: 5-6]. Бу дәвердә үк шул төбәкләрдә формалашып беткән ч-лаштыручы һәм ц-лаштыручы мишәр сөйләшләре булганлыгы бәхәссез. Ә кайбер тел үзенчәлекләре күчеп утыру, башка төрки һәм төрки булмаган кабиләләр белән аралашу, әдәби тел тәэсирендә соңрак барлыкка килгән. Моны мишәр сөйләшләре арасындагы аермалыкларның чагыштырмача аз булуы да раслый. Этнографик чыганакларда мишәрләр дүрт төркемгә бүлеп карала: Ока буе, Иделнең уң як яры, Иделнең сул як яры, Урал буе [16: 16-17].

Мишәрләр, Рус дәүләте чикләрен саклау максатыннан, башта көнчыгыш, соңрак XVI-XIX гасырлар аралыгында көньяк һәм көньяк-көнчыгыш юнәлешләргә таба күчереп утыртылган [15: 4]. Алга таба Россиянең төрле губерналарыннан килеп урнашкан мишәр сөйләше вәкилләре, казан татарлары кебек үк, көнбатыш себер татарлары сөйләше формалашуга үз йогынтысын ясаган [17: 12-13].

Хезмәттә анализлана торган [a] авазы мишәр диалекты сөйләшләрендә аралашучы халыкның катлаулы этник комплекс булуын исбатлый. Нигезен борынгы кыпчак кабиләләре тәшкил иткән бу этник төркем формалашуда маҗар, бортас, нугай, болгар компонентлары катнашкан. Ц-лаштыручы сөйләш нигезендә Идел буе, Кавказ алды җирләрендә таралып, болгарлар белән янәшә яшәгән маҗар кабиләләре ята. Монгол яулап алулары чорында бу кабилә Сура елгасының өске агымына кадәр менеп урнашкан, ә бер өлеше Кадом тирәләрендә утырган. Ә ч-лаштыру үзенчәлеге халык формалашуда этник яктан Иделнең аскы агымында яшәгән көнбатыш кыпчак кабиләләре катнашу белән бәйле. Шул рәвешле, мишәр диалекты сөйләшләрендәге ачык әйтелешле иренләшмәгән [a] авазы аның нигезендә бу җирләрдә яшәгәнлекләре тарих, этнография, археология фәннәре казанышлары белән расланган борынгы кыпчак кабиләләре булу белән бәйле. Ф.Исхаков төрки телләрдә [a] авазының дүрт төрле вариантта кулланылышын

билгели: гомумтөрки яссылыкта караганда, төрки телләргә рус теленнән кергән берәмлекләрдә очрый торган [а] авазы, татар һәм башкорт телләрендә кулланыла торган иренләшкән [а°], үзбәк теленә хас нык иренләшкән [o$^{a}$], һәм барлык башка төрки телләргә хас [а**] [6: 64]. Әмма бу бүленеш татар сөйләшләренә хас барлык үзенчәлекләрне яктыртып бетерми. Безнең карашыбызча, «башка барлык төрки телләргә хас» дигән вариантта нәкъ менә мишәр диалекты сөйләшләрендәге ачык әйтелешле иренләшмәгән [а] авазы күз алдында тотыла. Ареаль яктан бу вариант зур территорияне үз эченә алса да, үзенең компактлы урнашуы белән характерлана.

*[â] – бик ачык, казан арты-дөбъяз тибы.* Акустика һәм артикуляция характеристикалары белән нугай һәм казах телләрендәге [а] авазына якын. Мишәр сөйләшләрендә кулланыла торган вариант белән чагыштырганда күпкә арттарак ясала, иренләшмәгән [8: 85]. [а] авазының бу варианты татар сөйләшләрендә утрау рәвешендә дөбъяз, нократ татарлары, бастан, касыйм һәм нагайбәк изоглоссаларын тәшкил итә.

Казан арты җирләрендә бу изоглоссаның барлыкка килүе халык тарихына бәйле фактлар белән аңлатыла. Тарихи чыганакларда Казан ханлыгы җирләренә нугайларның килеп, шунда яшәп калулары турында мәгълүматлар шактый. Нугай этнонимы Алтын Урда дәүләтенең хәрби юлбашчысы Яссы Нугай исеме белән бәйләп карала. Күчмә тормыш рәвеше алып баруга карамастан, нугайларның Җәек елгасының аскы агымында Сарайчык исемле башкаласы булган. Моннан тыш Урда-базар һәм Нугай кала дигән шәһәрләре булганлыгы да мәгълүм [18: 105].

Алтын Урда таркалганнан соң, нугайлар Әстерхан, Себер, Казах, Кырым, Казан ханлыкларын төзүгә һәм ныгытуга үз өлешен кертә. XVI гасырның беренче яртысында Казан ханнарының нугайларга йөз тотуы билгеле. 1506 елда Казан ханы Мөхәммәд Әмин казанлылар һәм 20 меңлек нугай армиясе белән Түбән Новгородка бара. 1530 елда Казанга 30 меңлек нугай гаскәре килеп, казанлылар һәм чирмешләр белән бергә шәһәрне дошманнардан саклау сугышында катнаша. XVI гасырның 20 елларында башкалага Сәхиб Гәрәй белән күпсанлы оланнар, би һәм морзалар килгән. Әмма аларның күбесе казанлылар тарафыннан юк ителеп, калган 3 меңлек гаскәре белән Сафа Гәрәй 1530 елда качып китә. 1536 елда Казан ханы Сафа Гәрәй нугай морзасы Йосыф кызы Сөембикәне хатынлыкка ала. 1537 һәм 1540 елларда казанлылар, кырымлылар һәм нугайлардан торган гаскәре белән Сафа Гәрәй ике тапкыр Мәскәүгә яу белән бара. Тәхетеннән төшерелгән Сафа Гәрәй, гаскәр килсә, Казанны канкоюсыз алачагын, аны күпләрнең кабул итүен әйтеп, нугайлардан ярдәм сорый. Ярдәмгә түләү буларак, хан аларга тау ягын һәм арча ягын бирергә, ә Йосыф морзаның өлкән улына нугайлар белән бәйле керемнәрне һәм князь титулын вәгъдә итә [19: 184].

XIV-XVII гасырларда нугайлар Җаек һәм Идел елгалары буйларында көн күрә. Исмәгыйль белән Урак морзалар озак вакытлар Казан янәшәсендәге җирләрдә яшәгән. Ә Ханмирза Нократ елгасы буйларын яулап алып, аның халкы шунда утырып калган булырга мөмкин. Казан, Әстерхан ханлыкларын Рус дәүләте басып алганнан сон да, Идел белән Җаек арасында Нугай урдаларының иркен яшәүләре билгеле. Татарлар яши торган җирләрдә нугай этнонимы белән бәйле топнимнарның еш очравы бу халыкның татар халкы тарихында эзсез югалмавын раслый. Мәсәлән, Яшел Үзән районы Ачасыр авылында «нугай тавы», «нугай чишмәсе», Питрәч районы Шәле авылында «ногай коесы», «нугай кабере», Саба районы Тулешкә авылында «нугай атавы», «нугай елгасы», Биектау районы Олы Бәрәзә авылында «нугай очы», «нугай тавы» һ.б. [20: 123].

Касыйм хан рус дәүләте белән бәйләнештә булып, 1452 елда Касыймны бүләккә ала һәм Касыйм ханлыгын төзи. Бу территориядә нугайларның яшәп калуы шул тарихи вакыйгалар белән бәйле.

Татар теленең нагайбәк сөйләшенә дә [а] авазының әлеге варианты хас. Нагайбәкләр килеп чыгышлары белән, Ф.Стариков фикеренчә, чукындырылган нугайларга һәм мишәрләргә барып тоташа [21]. В.Витебский исә нагайбәкләр Казан ханлыгы алынганнан соң чукындырылган һәм Уфа губернасына күчереп утыртылган казан татарлары булырга тиеш дигән караштa тора [22]. Керәшен татарларының бер төркеме булган нагайбәкләр XIX гасыр урталарына кадәр Уфа губернасының Бәләбәй өязендәге Нагайбәк кальгасында яшәгән. 1842 елда алар, казак статусы алып, хәзерге яшәү урынына күчеп утырганнар. Нагайбәкләр үзләрен, Казан артыннан күчерелгәнлекләрен күз алдында

тотып, «иске ил керәшеннәре» дип атый [23: 38]. Бу кавемнең Казан арты, Арча ягыннан килгәнлеген Д.Исхаков та раслый [24: 4]. М.Әхмәтҗанов фикеренчә, нагайбәкләр тарихы Казан артындагы Апаз, Карадуган авыллары белән бәйле [25: 58-71]. Нагайбәкләрнең этник яктан нугайларга барып тоташуын да кире кагып булмый.

Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, татар теле формалашуда кыпчак, болгар телләре төп компонент булса да, нугай теле дә катнашып, тел субстраты күренеше буларак, аерым сөйләшләрдә билгеле бер авазлар, шул исәптән [а] авазының бик ачык, казан арты-дөбъяз тибы варианты буларак сакланган.

*[а*] – уртача ачык*, акустик һәм артикуляцион яктан [а°] һәм [а] вариантлары арасында тора. Ул, [а] авазының башка вариантлары белән беррәттән, нигездә, себер татарлары диалектлары, пермь һәм Башкортстан территориясендә таралган татар сөйләшләрендә очрый.

Себер татарлары теле, ап-ачык кыпчак элементларына, алтай телләре билгеләренә ия булып, Идел буеннан килгән татарларның һәм Бохара үзбәкләренең тел үзенчәлекләре йогынтысында формалашкан. Көнчыгышкарак киткән саен, татар сөйләшләрендә [а] авазының иренләшүе кими бара. Шуның нәтиҗәсендә уртача ачык вариант кулланыла торган күчмә зона барлыкка килгән. Башкортстан җирлегендә, көнчыгышка киткән саен, иренләшү кимү тенденциясе күзәтелсә, Татарстанда (алабуга, чаллы, зәй һ.б. урынчылыклар) бу вариант утраучык рәвешендә генә очрый. Керәшен татарлары сөйләшләрендәге бу күренеш төрле сөйләш, диалект вәкилләре катнашы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип уйларга нигез бар [23: 24].

Уртача ачык әйтелә торган [а] авазы варианты пермь татарлары сөйләшендә таралган. Д.Исхаков фикеренчә, бу урында яшәгән җирле кабиләләр татарлашкан. Пермь татарлары сөйләшен җентекләп өйрәнгән Д.Рамазанова бу мәсьәләгә киң туктала. Ул тасвирлаган материаллардан аңлашылганча, сөйләш урта һәм мишәр диалектларыннан берникадәр аерыла һәм алтай, шор, хакас телләре белән берникадәр уртаклыклар күзәтелә [26: 23]. Бу билгеләр телнең барлык ярусларында да булганга, пермь татарлары сөйләше формалашуда борынгы көнчыгыш-төрки компонент катнашканлык турында фикер йөртергә урын бар. Бу компонент пермь сөйләшен берникадәр дәрәҗәдә себер татарлары сөйләшләре, башкорт теле сөйләшләре белән якынайта. Бу очракта сүз остяк // иштяк кабиләләре турында барырга мөмкин [27; 28: 43]. Шул рәвешле, пермь татарлары сөйләшендәге уртача ачык [а] авазы сөйләшне башка төрки телләр белән якынайта һәм бу көнчыгыш-төрки компонент булу белән аңлатыла.

Татар милли теленең бер үзенчәлеге булган [а] авазы вариантларының кулланылыш үзенчәлекләрен анализлаганнан соң түбәндәге гомуми нәтиҗәләргә киленде. Татар теле материалын ареаль лингвистика фәне казанышлары контекстында тикшерү тел күренешләренең килеп чыгышы һәм таралышы сәбәпләрен аңлатырга мөмкинлек бирә. [а] авазы вариантларын билгеләү татар халкын формалаштырган этник компонентларны һәм тел үсешенә йогынты ясый торган экстралингвистик факторларны ачыкларга юл ача.

Телнең иң тотрыклы ярусларыннан саналган фонетик үзенчәлекләр татар сөйләшләрен бер-берсенә каршы куйса, гомумтөрки яссылыкта бер тел системасына керә торган берәмлекләр буларак анализларга нигез бирә. Шул нисбәттән татар сөйләшләренә түбәндәге билгеләр хас: урта диалект сөйләшләренә [а] фонемасының ике варианты кулланыла (уртача иренләшкән [а°] һәм казан арты-дөбъяз (нугай тибындагы) [â]). Мишәр диалекты ачык [а] авазы белән характерлана. Себер татарлары сөйләшләренә, нигездә, уртача ачык [а*] вариант хас. Нык иренләшкән [$о^а$], локаль характерда булып, урта һәм тубыл-иртыш диалектлары кысаларында хосусый бер система булып тора. Бу вариант соңрак формалашып, татар диалект системасына килеп кергән һәм мөстәкыйль бер зона барлыкка китергән. Ә татар теленең себер диалекты сөйләшләрендә бу вариант үзәгендә үзбәк теле үзенчәлеге торган тирбәлеш зонасын барлыкка китергән. Шулай итеп, [а] авазы вариантлары татар милли теле диалектларын һәм сөйләшләрен характерлау максатыннан төп дифференциаль билгеләрнең берсе буларак кулланылырга хаклы.

Татар сөйләшләре өчен характерлы булган уртача иренләшкән [$а^о$] һәм ачык әйтелешле [а] вариантлары төп ике форманы тәшкил итә һәм төрки телләр арасында татар теленең урынын билгели. Уртача иренләшкән [$а^о$] нык иренләшкән [$о^а$] вариантына караганда киңрәк

ареалда таралып, әлеге форма кулланыла торган башка ареаллар белән чагыштырганда беренчел булган Урта Идел, Чулманның түбәнге агымы, Урал буйларына таралган сөйләшләрдә күзәтелә. Ә оренбург сөйләшенең ык, каргалы, бузулук урынчылыклары тирбәлеш зонасы барлыкка китергән. Ачык әйтелешле [а] варианты изоглоссалары шактый киң булып, татар милли теленең таралыш чикләрен һәм татар халкы формалашуда кыпчак кабиләләренең әһәмиятен күзалларга мөмкинлек бирә. Ык иренләшкән [o[a]] һәм казан арты-дөбъяз (нугай тибындагы) [â] вариантлары татар милли теле формалашуда үз эзен калдырган башка төрки телләрнең субстрат күренеше буларак аңлатыла. Бу очракта сүз нугай, фин-угор, үзбәк телләре турында бара. Ә уртача ачык [а] авазы тасвирланган вариантлардан иренләшкән һәм иренләшмәгән вариантларның катнашу чикләре күрсәткече булып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теле [а] авазы вариантлары кулланылышына нигезләнгән үзенчәлекле система тәшкил итүе, шул ук вакытта төрки телләр яссылыгында гомуми билгеләргә ия булуы белән характерлана.

**Әдәбият**


1. *Бородина М.А.* Развитие ареальных исследований и основные типы ареалов // Взаимодействие лингвистических ареалов. М.: Наука, 1980. 272 с.
2. *Гаджиева Н.З.* Проблемы тюркской ареальной лингвистики. М., 1975. 304 с.
3. *Хисамова Ф.М.* Туган тел һәм милләт язмышы // Татарика. 2014. №1. Б. 23-35.
4. *Юсупов Ф.Ю.* Изучение татарского глагола. Казань: Татар. кн. изд-во., 1986. 288 с.
5. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954. 108 б.
6. *Исхаков Ф.Г.* Характеристика отдельных гласных современных тюркских языков // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч I. Фонетика. М. 1955. С. 60-114
7. *Мәрҗани Ш.* Мөстафәд әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. Казан, 1989. 126 б.
8. *Бурганова Н.Б.* Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья // Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1978. С. 76-95.
9. *Серебренников Б.А.* О некоторых признаках Волгокамского языкового союза // Языковые контакты в Башкирии. Уфа, 1972. С. 7-17.
10. *Грузов Л.П.* Историческая грамматика марийского языка. Йошкар-Ола, 1960. 212 с.
11. *Халиков А.Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1978. 160 с.
12. *Износков И.А.* Материалы для истории христианского освещения мордовцев Казанского края. М., 1885. 391 с.
13. *Матвеев Т.М.* Краткий обзор чувашских диалектов (опыт районирования) // Материалы по чувашской диалектологии, I. Чебоксары: Чувашкнигоиздат, 1960. 196 с.
14. *Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 295 с.
15. *Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 272 с.
16. *Орлов А.М.* Мещера, мещеряки, мишаре. Казань, Татар. кн изд-во, 1992.110 с.
17. *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек. Казан, 1961. 240 б.
18. *Булатов А.Б.* Некоторые материалы о ногайско-татарских связях в прошлом // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1974. 252 с.
19. *Перетяткович Г.* О роли ногайских племен в жизни Казанского ханства // Поволжье в XV-XVI веках. Очерки из истории края и его колонизация. М., 1877. 338 с.
20. *Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. Беренче китап. Казан, 1992. 147 б.
21. *Стариков Ф.М.* Откуда взялись казаки. Оренбург, 1884 с.
22. *Витебский В.И.* Сказки, загадки, песни нагайбаков Верхнеуральского уезда Оренбургской губерни // Тр. 4-го археологического съезда России. Т. II. Казань, 1851 с.
23. *Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М.: Наука. 1986. 248 с.
24. *Исхаков Д.М.* Этнографическое развитие нагайбаков до первой четверти XX в. // Нагайбаки. Казань, 1995. 145 с.
25. *Ахметзянов М.И.* К этнолингвистическим процессам в бассейне р. Ик (по материалам шедже-ре) // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, ИЯЛИ КФАН СССР, 1985. 127 с.
26. *Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говоров пермских татар. Казань, 1996. 240 с.
27. Народы Сибири. М.-Л., 1956. 1083 с.
28. *Исхаков Д.М.* Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX века // К вопросу об этнической истории татарского народа. Казань, 1985. С. 36-65.

# ФОНЕТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА, ОБУСЛОВЛЕННЫЕ АРЕАЛОМ ЕГО РАСПРОСТРАНЕНИЯ

**Мадина Рашидовна Саттарова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
m-sattarova@mail.ru.

Начиная с 1970-80-х гг. ученые-лингвисты активно исследуют распространение языковых явлений в пространственной протяженности. В трудах таких известных ученых, как Г.Ф.Благова, М.А.Бородина, Н.З.Гаджиева, А.Б.Джураев, Б.А.Серебренников, Ф.Ю.Юсупов, определены цели и задачи, перспективы ареальных изысканий на материале тюркских языков. Несмотря на то что на протяжении многих лет ведется изучение особенностей тюркских языков, распространенных на огромной территории, исследования в данном направлении не теряют своей актуальности. Важное значение имеет анализ лингвистического материала, накопленного в результате изучения говоров и диалектов тюркских языков с точки зрения ареалогии. Исследования в данном русле позволят систематизировать общие и специфические явления в изучаемом материале, создать языковую модель отдельных тюркских языков. В данной статье рассматривается одно из дифференцирующих явлений татарского языка в связи с ареалом его распространения.

**Ключевые слова:** татарский язык, гласные звуки, история языка, татарская диалектология, диалектологический атлас, ареальная лингвистика.